УДК 74/76

*Р.Н. Галиева*

# 1920 ЕЛЛАР ТАТАР ПЛАКАТЫН ҮСТЕРҮ ЧЫГАНАГЫ БУЛАРАК РЕВОЛЮЦИЯГӘ КАДӘРГЕ ТАТАР СӘНГАТИ МӘДӘНИЯТЕНЕҢ ТРАДИЦИОН ҺӘМ ЯҢА ФОРМАЛАРЫ

В статье рассматриваются те формы татарской дореволюционной художественной культуры, которые в той или иной мере послужили источниками для развития искусства татарского плаката 1920-х гг. Это традиционные виды татарского искусства – шамаиль, ляухэ, а также новые виды – календари, активно развивавшиеся с последней трети XIX в., и театральные афиши, появившиеся в нач. XX в. Их основу составлял арабографичный текст, часто во взаимодействии с изобразительными элементами, что стало характерным и для татарского плаката 1920-х гг.

**Ключевые слова:** национальное искусство, татарская художественная культура, шамаиль, ляухэ, календарь, театральная афиша, арабская графика.

The article examines those forms of the Tatar pre-revolutionary artistic culture, which in one way or another served as sources for the development of the art of the Tatar poster of the 1920s. These are traditional types of Tatar art – shamail, lyaukhe, as well as new types – calendars, which have been actively developing since the last third of the twentieth century, and theatrical posters that appeared at the beginning of the XX century. They were based on an arabographic text, often in interaction with pictorial elements, which became characteristic of the Tatar posters of the 1920s.

**Keywords:** national art, Tatar art culture, Shamail, Liauhe, calendar, theatrical poster, Arabic graphics.

1920 елларда Татарстанның плакат сәнгате – республика сынлы сәнгатендә илебез тормышындагы революцион үзгәрешләр йогынтысында барлыкка килгән мөһим вакыйга. Татар плакатының (бу очракта без татар телендәге плакатны күз алдында тотабыз) үсеше республикабызда әлеге сәнгать төренең характерлы үзенчәлеге булып тора. Ул – гасырлар дәвамында декоратив-гамәли һәм каллиграфия сәнгатьләре рәвешендә үсеш кичергән традицион татар сәнгати мәдәнияте өчен өр-яңа күренеш. Чөнки кеше һәм хайван сурәтләрен рәсемгә төшерү ислам дине тарафыннан катгый рәвештә тыелган була. Шул ук вакытта татар сәнгати мәдәниятендә шәмаил һәм ләүхә кебек традицион декоратив-гамәли сәнгать формалары яши, аларда текст тасвирый элементлар белән бергә үрелеп бара, ә XIX гасырның соңгы чирегендә һәм XX гасыр башында календарь һәм театр афишасы кебек татар мәдәнияте өчен яңа формалар барлыкка килә һәм актив үсә башлый. Соңыннан аларның да татар плакаты үсешенә йогынтысы зур була.

Плакат – сынлы сәнгатьнең бер төре, күзгә ташлана торган сурәт, аның төп бурычы – еракган ук тамашачы игътибарын үзенә җәлеп итү һәм аңа нәтиҗәле йогынты ясау [Аполлон, с. 446]. Плакат кыска лозунгны, кайвакыт өстәмә текст һәм информацион, агитацион, уку-укыту яки реклама максатларында эшләнгән сурәтләрне үз эченә ала.

1920 елларда татар плакаты рус плакатының фундаменталь сәнгать принципларына нигезләнеп барлыкка килә. Әмма татар плакатының үзенчәлекле үсеше 1920 еллар ахырына кадәр татар мәдәниятенең нигезе булган гарәп графикасын саклап калу белән бәйле. Бу – ике тел һәм ике мәдәниятнең үзара ярашуын чагылдырган кабатланмас оригиналь күренеш. Рус плакатының үзенчәлекләрен һәм җирле милли колоритны үзенә сеңдергән татар (шулай ук ике телле – рус-татар) плакаты үзенә генә хас сыйфатлар белән дә аерылып тора.

1920 елларда татар плакатлары картинасы үтә нык чуар: ул кызыклы гына сәнгати эшләрне дә, лубоктан төшерелгәнне хәтерләткән күп кенә профессиональ булмаган плакатларны да үз эченә алып, әлеге яңа юнәлештә рәссамнарның беренче адымнарын да чагылдыра. Татар плакаты халык белән аралашу проблемаларын хәл итә, татарларга үз ана телендә нәрсәдер эшләргә чакыра яки агитацияли. Рәссамнар еш кына татарча текст белән янәшә рус телендәгесен дә бирә, шулай ук милли персонажларны – татар ирләрен яки хатын-кызларын сурәтли. Бу чорның плакатлары туры сүзле һәм үтемле булуы белән аерылып торалар, литография техникасында, кайчагында кулдан эшләнәләр, сирәк кенә рәссамнар линогравюрага да мөрәҗәгать итәләр. 1920 еллар башы плакатларында төп темаларны хәрби пропаганда, героик, агарту плакатлары, социаль активлыкка, гигиенаны саклауга чакыру, наданлык һәм ачлыкка каршы көрәш, укый-яза белүне һәм мәдәниятне пропагандалау тәшкил итә. Бу чорда татар плакатындагы иң характерлы сыйфатларның берсе – аның аскы яки өске өлешендә рус текстын кабатлаучы гарәп графикалы татар тексты булу. Басма нәсехнең гадәти почеркы, сирәк очракларда куфи яки тәгъликъ элементлары кулланыла. Еш кына плакатта, тагын да көчлерәк милли төсмер өстәп, аның төп асылыннан аерып торган татар орнаменты да бирелә.

XX гасыр башында татар театрының барлыкка килүе һәм үсеше белән бәйле театр афишаларын 1920 еллар татар плакатының турыдан-туры элгәрләре дип санарга мөмкин. Театр плакаты жанры реклама плакаты белән мөстәкыйль сәнгать төре арасындагы сизелер-сизелмәс кенә чиктә яши. Театр плакатының образлы чишелеше үзе яктырткан театраль постановканың сәнгати үзенчәлегенә бәйле. Еш кына нәкъ менә афиша театр тамашачысына уңай йогынты ясый. Р.Р. Солтанова язганча, XX гасыр башы татар афишалары мәгълүматка байлыгы, аңлатма текстларының озынлыгы белән аерылып тора, кайвакыт алар милли орнамент һәм аның элементлары белән бизәлә.

Текст, гадәттә, татар телендә булып, әмма еш кына ике телдә дә языла. Шуңа күрә татар орнаментын хәтерләткән гарәп язуы (еш кына нәсех стилендә) төп декоратив вазифаны башкара. XX гасырның беренче унъеллыгы татар театр афишасы өчен декоративлык, гарәп язуын һәм милли орнамент куллану, татар кулъязма һәм басма китапларын бизәү алымнарыннан (заставкалар, каймалар, виньеткалар, зигзаг һәм ромблар) файдалану хас [Султанова, с. 16].

XVIII гасыр ахырыннан башлап шәмаилләр – дини әһәмияткә ия һәм Коръәннән бер аять яки бөтен бер сүрәне үз эченә алган һәм гарәп каллиграфиясе традицияләрендә башкарылган дивар паннолары татар көнкүрешенең үзенчәлеге булып тора. Шәмаил сүзе гарәп теленнән алынган (сыйфат, абруй мәгънәсендә), татарларда ул – каллиграфик текстлар һәм символик-сюжетлы мотивлар белән бизәп башкарылган панно. Беренче шәмаилләр пыялада майлы буяу белән ясалган һәм арткы яктан фольга белән капланган. Кайчагында шәмаилләр язу карасы, тушь һәм төсле үсемлек буяулары белән ясалып, сурәтләр пыяла астына урнаштырыла. XIX гасыр ахырыннан литография (шул исәптән төсле) техникасында башкарылган басма шәмаилләр киң тарала.

Шәмаил татар йортлары, мәчетләр, мәктәп һәм мәдрәсәләр интерьерының аерылгысыз өлешен тәшкил итә, дини генә түгел, ә эстетик әһәмияткә дә ия була. Ул изге, тылсымлы мәгънәгә ия орнаменталь-декоратив композициядән гыйбарәт булып, каллиграфик тексттан гына түгел, ә орнаменталь бизәк, Мәккә, Мәдинә, Константинополь (Истанбул), Кәгъбәдәге кара таш, Иерусалим һәм башка мөселман изге урыннарының стильләштерелгән сурәтләреннән, архитектура элементларыннан да тора [Плакат Советского Востока..., с. 74]. Кайчакта шәмаилгә метафорик сурәт тә килеп керә. Гадәттә, коткарылу символы булган Көймә, Агач образы сурәтләре төшерелә. Шәмаил шулай ук картинага охшаган булырга да мөмкин, анда дини архитектура корылмалары да чагылыш таба. Гарәп язулы татар шәмаилләре арасында мөселман ай атамаларын, мөнәҗәт, бәетләрдән һ.б. алынган шигъри юлларны, афоризм, әйтем, мәкальләрне үз эченә алганнары да бар [Гилемшин, с. 31]. Шәмаилдәге тамгалар арасында ассоциацияләрнең катлаулы системасы авторларга визуаль структураның өстенлек итүче элементын билгеләргә мөмкинлек бирә. Бу текст та, икенчел дәрәҗәле элементлар да булырга мөмкин. Шулай ук кайбер басма шәмаилләрдә татарча текстлар да очрый, алар шәмаилне халыкның киңрәк даирәсенә юнәлтеп, аңлату-төшендерү бурычын үтиләр.

Татарстан территориясендә шәмаилләр киң тарала һәм бу – плакат сәнгате туура иң мөһим алшартларның берсе булып тора. Аның сәнгать принциплары, тамашачыга юнәлтелгән үзләштерү законнары һәм таләпләре ягыннан, плакат сәнгатендәгегә бик охшаш. Шәмаилдә төп идея-эчтәлекне каллиграфик башкарылган изге сүзләрдән торган текст тәшкил итә, ә сурәт тамашачыларга визуаль мөрәҗәгать итү-

нең өстәмә элементы булып тора. Плакат сәнгатендә сурәт һәрвакыт лозунг һәм текст белән логик һәм мәгънәви бәйләнештә тора, биредә функциональ фундаменталь принципларда ике төрле сәнгать жанры – плакат һәм шәмаилнең композицион график элементларының үзара йогынты ясашу охшашлыгын ачык күреп була. Шәмаил һәм плакатларның образлар рәте һәм эчтәлек ягы агарту, мәгълүмат тапшыру, нәфис каллиграфик чишелеш ярдәмендә сәнгати зәвыкны үстерү кебек арадаш функцияләргә ия. Шәмаилнең үзендә барлык элементлар да структурлаштырылган һәм композицион корылышның визуаль принципларына буйсындырылган, шул ук принциплар плакатлар өчен дә актуаль. С.М. Червонная фикеренчә, шәмаилдәге сурәтләр еш кына каллиграфик тамгалар белән симбиоз бәйләнештә тора, хәрефләр үсемлек яки архитектура элементларына күчә [Червонная, 1987, с. 266]. Дини текстларның катлаулы бормалы язуы шәмаилләрнең орнаменталь нигезе һәм томаланган сурәтләре белән аһәңдәш үзара бәйләнеш тудыра, ә соңрак шрифтларга һәм хикмәтле бизәлешкә өстенлек бирү татар вакытлы матбугатында, афиша һәм плакатларда чагылыш таба (бу шулай ук Татарстанның шрифт сәнгатенә дә күчә). Культурологик планда шәмаил әһәмиятле роль уйный, ул рәссамнарга һәм тамашачыларга ислам сәнгатенең традицион формаларын кабул итүдән сынлы станок сәнгатенә күчешне тәэмин итә [Червонная, 2008, с. 354].

Шәмаилнең бер төре – ләүхә (гарәп телендә – язулы такта, элмә такта, полотно-картина). Татар рәссамнары Коръәннең аять һәм сүрәләрен, дини эчтәлектәге башка текстларны чигәләр, ә тукымага төшерелгән бормалы гарәп язуын пыяла астына урнаштыралар. Ләүхә, шәмаил кебек үк, диварга эленә [Валеева-Сулейманова, с. 654]. Шәмаил татар телле мөселман халкы тормышында зур роль уйнаганга күрә, Совет власте аны агитация сәнгате сыйфатында файдаланырга омтыла. 1925 елда Сулфның («Сәнгатьнең сул фронты») татар филиалы рәссамнарының икенче күргәзмәсендә А.Г. Платунованың пыялада эшләнгән, үзенең тылсымлы дини мәгънәсен югалткан һәм бары тик форма һәм техника ягыннан гына шәмаил белән бәйләнешен саклаган «агитка»лары күрсәтелә [Константин Чеботарев..., с. 9]. 1920–1930 еллар чигендә «югарыдан революция» гарәп язуын юкка чыгара, бу – СССРда мөселман цивилизациясенең бетерелүен аңлата [Хабутдинов, с. 29].

XIX гасырда татар халкы арасында киң таралыш алган шәмаилләр Татарстан плакат сәнгатен үстерүнең ачыктан-ачык алшартларын тәшкил итәләр. Шәмаил сәнгате Татарстан территориясендә сәнгать әсәрләренең иң нәфис төрләреннән берсе була, ул җирле милли мәдәниятнең күптөрлелеген һәм үзенчәлекләрен үзендә туплый һәм шул чорның феноменына әверелә. Бер яктан караганда, формасы һәм кулланылышы буенча шәмаилләр нәкъ плакат сәнгатенең үзенчәлекләренә ия булып чыга. Әмма эчтәлек ягыннан якын килсәк, үз сәхифәләрендә шул чорның иҗтимагый-сәяси һәм реклама

мәгълүматларын, кыска мәкаләләрне һәм белешмә материалны яктырткан календарьлар плакат сәнгате белән аеруча аваздаш. Шул ук вакытта календарьлар плакатларның эчтәлеге, аларның реклама функцияләре һәм пропаганда бурычлары визуаль плакат сәнгате өчен нигез әзерли.

Татар плакатлары барлыкка килүдә календарьларның әһәмияте гаять зур. Календарь – бәйрәмнәр, тарихи вакыйгалар, айлар, атна көннәре, саннар, шулай ук зур булмаган сәнгать әсәрләре турында белешмәләрне үз эченә алган басма [Миннуллина, Новицкая, 2006, с. 180]. Ай календаре «камәрия» көннәрне исламның дини йолалары буенча санап төзелгән, кояш календаре «шәмсия» көндәлек дөньяви максатларда кулланылган [Вагапова, с. 55]. XIX гасыр азагы – XX гасыр башында алар «өстәл календаре» булып хезмәт итәләр. Ә бу исем аларга китап-брошюра белән тышкы охшашлыклары булу аркасында бирелә. Мәгърифәтче һәм галим Каюм Насыйриның календарь басмалары милли матбугатның беренче карлыгачлары саналган тәүге календарьлар булып тора. Календарьның беренче басмасы 1870 елда дөнья күрә. Тышкы кыяфәте белән ул кечкенә генә форматлы брошюраны хәтерләтә. Кайбер календарьларның титул битләрендә орнамент урнаштырыла. Календарьда, гамәли мәгълүматлардан тыш, кайвакыт мәчетләрнең, Сөембикә манарасының кечкенә иллюстрацияләре, шулай ук астрономик карта һәм схемалар урын алган. Полиграфик эшләнеше ягыннан календарьларның ертып алына торган дивар, плакат рәвешендәге дивар, кесә һәм брошюралар рәвешендәге өстәл календарьлары төрләре билгеле. Календарьда саннар, айлар, даталар һәм бәйрәмнәр исемлеген генә үз эченә алган белешмә материал гына түгел, бәлки тормышның төрле өлкәләренә караган кыска информацион мәкаләләр, белдерүләр, реклама, легенда һәм риваятьләр, табышмаклар, биографик мәгълүматлар, фотоматериаллар кебек мөстәкыйль чыганаклар да басыла [Миннуллина, 2015, с. 120]. Басма календарьлар төрле эчтәлекле белемнәрне массаларга җиткереп, төрле мәсьәләләр буенча (тормыш-көнкүрештә кирәкле киңәшләрдән, инструкция һәм рецептлардан башлап, яңалыкларга кадәр) халыкка мәгълүмат таратып, үзенчәлекле белешмәлекләр ролен үтиләр. Шунысы игътибарга лаек, календарьларны кайвакыт мөселман бәйрәмнәре күрсәтелгән кайбер басма шәмаилләрдә дә очратып була [Шамсутов, с. 38].

Шул рәвешле, татар плакаты барлыкка килү һәм үсешенең тарихи-мәдәни алшартлары графика сәнгатенең шәмаил һәм календарьлар кебек төрләре белән тыгыз бәйләнгән. Сәнгати образ һәм композицион чишелеш ягыннан 1920 еллар Татарстан плакаты сәнгатенә шәмаилләр аеруча якын тора, аларда сурәтләрнең бормалы гарәп язуы белән ярашу традициясенә нигез салынган була инде. Әмма эчтәлек һәм функцияләр буенча Татарстан плакат сәнгате өчен ныклы нигез хезмәтен календарьлар үти. Алар гамәли характерда булып, җәмгыять тормышының төрле өлкәләрен колачлаган мөһим мәсьәләләр-

не хәл итә. Татар плакаты үзенең барлыкка килүендә татар сәнгати мәдәниятенең элгәреге график тәҗрибәләре традицияләренә, мотив һәм кануннарына таяна, яңа заман куйган таләпләр, яңа тенденцияләр нигезендә яңа графика телен гомумиләштереп, алга таба тагын да тирәнрәк үсеш кичерә.

**Әдәбият**


Аполлон. Изобразительное и декоративное искусство. Архитектура: Терминологический словарь / под общ. ред. А.М. Кантора. М.: Эллис Лак, 1997. 736 с.

*Вагапова Ф.Г.* Становление искусства татарской рукописной и печатной книги XVII – начала XX вв.: стилистика и символика: дис. ... канд. искусствоведения. Казань, 2015. 234 с. (Рукопись)

*Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Ляухэ // Татарская энциклопедия: в 6 т. Т. 3: К–Л. Казань: Ин-т татарской энциклопедии АН РТ, 2006. 654 с.

*Гилемшин Ф.Ф.* Особенности текстового содержания арабографических шамаилей // Грамота. 2017. № 8(74): в 2-х ч. Ч. 2. С. 29–32.

Константин Чеботарев. Александра Платунова. Живопись. Графика. Из музейных и частных собраний / авт.-сост.: Н.М. Валеев, О.Л. Улемнова, авт. вст. ст. О.Л. Улемнова. Казань: Заман, 2018. 384 с.: ил.

*Миннуллина Л.З.* Татарские печатные календари XIX – начала XX в. Казань: Заман, 2015. 175 с.

*Миннуллина Л.З., Новицкая И.А.* Календарь // Татарская энциклопедия: в 6 т. Т. 3: К–Л. Казань: Ин-т татарской энциклопедии АН РТ, 2006. 180 с.

Плакат Советского Востока 1918–1940: альбом-каталог / сост. М. Филатова при участии В. Бобровникова. М.: Изд. Дом Марджани, 2013. 316 с.

*Султанова Р.Р.* История татарского театра в плакатном искусстве. Казань, 2017. 352 с.

*Хабутдинов А.* Между модернизмом и атеизмом, от арабского шрифта к латинице: тюркские народы СССР в 1920-е годы // Плакат Советского Востока 1918–1940 / сост. М. Филатова при участии В. Бобровникова. М.: Изд. Дом Марджани, 2013. – С. 25–29.

*Червонная С.М.* Искусство Татарии. М.: Искусство, 1987. 352 с.

*Червонная С.М.* Современное исламское искусство России. М.: Прогресс-Традиция, 2008. 552 с.

*Шамсутов Р.И.* Слово и образ в татарском шамаиле от прошлого до настоящего. Казань: Татар. кн. изд-во, 2003. 199 с.



***Галиева Рената Наил кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты аспиранты*